# Әхлак кешене бизи

Бел, әхлак гүзәллеге камил акыл аша шәригать кануннарын үтәүдән барлыкка килә. Акыл исә - Аллаһы һәрберебез күңеленә салган яктылык ул. Шул яктылык ярдәмендә кирәкле һәм абстракт (теоретик) белемнәрне кабул итү җиңеләя.

Акыл аша булдырылганнардан иң яхшысы - гүзәл әхлак сыйфатлары һәм культуралылыктыр. Акылдан тыш культура юк, мәдәниятлектән башка акыл камиллеккә ирешә алмый. Шуңа күрә этика матурлыгына һәм мәдәниятккә өйрәнү - акылны баетудыр, һәм болар барысы да тырышлыкка һәм бары әхлакка омтылуның дәлиледер.

Югары әхлак - һәркемнең үз ихтыярында. Һәм шуңардан 2 төрле асыл сыйфатлар барлыкка киләдер:

- гүзәллек - мактауга лаек;
- әшәкелек - кире кагылырга, кисәтелергә тиеш.

Мактауга лаек әхлаклылык - кайбер кешеләрдә тумыштан килгән сыйфат, шуңа да карамастан, ул даими рәвештә белем туплау, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең үз-үзен тотышын һәм әхлагын өйрәнү, аның тәрҗемәи хәле белән танышу аша рухны баету.

Аллаһы Тәгалә кешене мөселман итеп яралта. Әмма тора-бара бозык әхлак аны биләргә мөмкин. Аннан үз-үзеңне билгеле бер тәртипкә күнектереп һәм контрольдә тотып, яңа белемнәр алып, гүзәл этика һәм культурага ия булып кына арынып була.

Югары әхлак кешеләр белән аралашканда туплана. Ләкин яхшы кешеләр белән аралашканда - югары әхлак нормалары, начар кешеләр белән аралашканда бозык әхлак сеңә.

Мөхәммәд Пәйгамбәр (аңа иминлек насыйп итсен) әйткән: *«Кыямәт көнендә кешеләр бер урынга җыелырлар, һәркайсы үз дусты белән килер. Шуңа күрә һәркем нинди кеше белән дус булуын хәзер үк истә тотсын»*. Шушы гыйбарәне Әбү Дауд ишеткән булган. Шулай итеп, һәр акыл иясе - кеше, холкын камил итеп тәрбияләү максатыннан, белем алырга, үзендә яхшы сыйфатлар булдырырга тырышсын. Мөстәкыйль, ирекле кеше бул: үзеңнең хәләл көчең белән мактау-ихтирам казан, ата-бабаларың ирешкән данга таянма, үз хезмәтең белән дан ал, әхлаксыз һәм мәдәниятсез кеше булма.

Аллаһы Тәгалә кешене гүзәл, камил итеп яралтты һәм аңа ике сыйфат бирде:

- фикерләү көче, акылы, уйлап эш итүе һәм белеме белән фәрештәгә тиң яралтты;
- бозыклыгы, комсызлыгы, бирәнлеге белән хайванга тиң итте.

Кем дә кем үз тырышлыгын фикерләү, уйлап эш итү, белем туплауга юнәлдерсә, гүзәл әхлакка һәм изге эшләргә ия булса - ул фәрештә кебек саф һәм күркәм әхлаклы булыр, олы ихтирамга тарыр.

Әгәр кем дә кем үз тырышлыгын бозыклыкка юнәлтеп, физик, җенси, хайвани ләззәтләргә омтылса, хайван кебек ашаса - аның урыны хайваннар арасында.

Пәйгамбәр (аңа иминлек насыйп итсен) әйтте: *«Мин гүзәл әхлакны камилләштерер өчен җибәрелдем»*.

Коръән-Кәримдә әйтелгәнчә («Әгъраф» сүрәсе, 199нчы аять): *(«Ий, Рәсүлем) син түземлелек юлын тот (киң күңелле бул, кешеләрне кичерә бел). Игелеккә чакыр вә җаһилләрдән ерак тор».*

*(«Татар мөселман календаре»ннан)*

# Юмартлык

Бөек китабыбыз Коръән-Кәрим адәм балаларын юмарт булырга өнди. Ни соң ул юмартлык? Юмартлык – ярдәм итүне аңлата. Һәрберебезгә дә мәгълүм – тормышыбызда төрле кешеләр бар: көчлеләр дә, зәгыйфьләр дә. Байлар һәм ярлылар, галимнәр һәм наданнар бергә яши. Ислам шәригате буенча бай, көчле һәм куәтле кешеләр фәкыйрь, зәгыйфь кешеләргә ярдәм итәргә тиешләр. Аллаһы Тәгалә Коръән-Кәримдә: *«...аларның малларында сорануларга һәм мохтаҗларга өлеш бар»*, – ди («Әз-Зәрият», 19 нчы аять).

Пәйгамбәребез юмартлык хакында бер хәдис-шәрифендә әйткән: *«Юмартлык – ботаклары дөньяның әченә сузган җәннәт агачларыннан берседер. Кем бу агач ботакларының берсеннән тотса, ул бөтен кешене җәннәткә тартыр. Саранлык – ботакларын дөньяга сузган җәһәннәм агачларыннан берседер. Кем ул агачның ботакларыннан тотса, ул ботак та кешене җәһәннәмгә тартыр»*. Тагын бер хәдисендә: *«Шик тә юк, юмарт кеше Аллаһыга, кешеләргә вә җәннәткә якын, җәһәннәмнән ерак булыр. Саран кеше Аллаһыдан, кешеләрдән вә җәннәттән ерак, җәһәннәмгә якын булыр»*, – дип әйтелә.

Риваятькә күз салыйк. Кыямәт көнендә дүрт төрле җәмәгатьне хисапсыз һәм газапсыз оҗмах ишекләренә китерерләр. Аларның әүвәлгесе - гыйлемнәре белән гамәл кылган галимнәр, икенчесе - хәләл мал белән хаҗ кылучылар, өченчесе - шәһитләр (Аллаһы юлында көрәшеп үлгәннәр), дүртенчесе - хәләл мал белән юмартлык кылганнар. Болар оҗмахка әүвәл керер өчен бәхәсләшерләр.

Аллаһы Тәгалә боларга хөкем итәр өчен Җәбраил фәрештәне җибәрер. Җәбраил фәрештә әүвәл шәһиттән сорар: «Син нинди гамәл сәбәпле оҗмахка әүвәл



керергә тиешсең?» Шәһит әйтер икән: «Аллаһы ризалыгы өчен сугышта шәһит булдым – шуның өчен оҗмахка әүвәл керергә телим». Җәбраил фәрештә сорар: «Шәһитлек савабын кемнән ишеттең?» «Галимнәрдән ишеттем», – дип җавап бирер шәһит. Җәбраил фәрештә әйтер: «Галим сиңа остаз икән, шуңа күрә әүвәл оҗмахка керә алмассың, әдәпсезлек булыр». Шуннан соң Җәбраил галәйһис-сәлләм хаҗидан сорар икән. Хаҗи әйтер: «Хаҗ кылдым, хаҗ савабы өчен оҗмахка керергә телим». Җәбраил галәйһис-сәлләм әйтер: «Хаҗ савабын кемнән ишеттең?» Хаҗи: «Галимнәрдән ишеттем”, - дияр. «Остазыңнан әүвәл керә алмассың», – дигән җавап булыр. Моннан соң юмарттан сорар, юмарт җавап бирер: «Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен юмартлык кылдым, шуның өчен әүвәл керергә телим». Җәбраил: «Юмартлык савабын кемнән ишеттең?» – дип сорагач, «Галимнәрдән», – дип җавап бирер. «Галимнәр сиңа остаз булган икән, алардан әүвәл оҗмахка керә алмассың». Галимнәр шул вакытта Аллаһы Тәгаләгә дога кылырлар: «Йә Раббыбыз! Шушы юмартларга остаз булсак та, гыйлемне юмартларның тәрбиясендә алдык. Әгәр юмартлар хәер-иман кылмаса, без укып галимнәр була алмас идек». Аллаһы Тәгалә боерыр: «Галимнәр дөрес әйтте, оҗмах сакчысы, ишеген ач, әүвәл юмартлар оҗмахка керсен!»

Ошбу риваятьтән мәгълүм булды – Аллаһы Тәгалә каршында юмартлыкның дәрәҗәсе бик олы. Юмартлык кылу белән малыбыз кимемәс, юмартлык байлыкка сәбәп булыр. Риваять буенча, бер кеше тиешле хисапка җиткән малыннан зәкят бирмәсә, Аллаһы Тәгалә ул кешенең малын бәрәкәтсез итәр. Әгәр бер кеше Ходай Тәгаләгә дога кылмаса, ул кешенең хаҗәтләре үтәлмәс. Шуңа күрә җаныбыз тәндә һәм гакылыбыз исән чакта яхшылыкны, изгелекне истә тотып, Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәләрдән тыелып, эшләргә кушканнарын үтәп яшәргә тиешлебез.

Коръән-Кәримдә әйтелә: *«Ходай ризалыгы өчен малларыннан садака кылган кешеләрнең мисалы – бер бөртек орлык мисалы. Чыгарды ул орлык җиде башак, һәр башагында булыр бер йөз бөртек. Бәс, бер бөртектән җиде йөз орлык булыр. Ягъни бер садаканың савабы җиде йөзгә ашар. Ходай Тәгалә теләгән кешеләренә җиде йөздән дә арттырыр. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте киңдер!»*

Садака кемгә бирелергә тиеш? Аллаһы Тәгалә «Тәүбә» сүрәсендә әйтә: *«Хакыйкатьтә – садакалар бирелер: фәкыйрьләргә, мескеннәргә, Аллаһы юлына, ягъни динебезне ныгыту өчен, мәсәлән, мәдрәсәләр файдасына, яңа мәчет төзелешләренә».*

Ходайга шөкер, яңа мәчетләр салына, халыкка миһербанлылык, гаделлек, рәхимлелек сыйфатларын тәрбияли торган мәдрәсәләребез эшли. Ошбу изге эшләр дәвамы өчен, динебез үсүе, ныгуы өчен тапшырылган садакаларны, күрсәткән ярдәмнәрне, йә Раббым, кабуллардан кылсаң иде! Шушы садакаларның, ярдәмнәрнең бәрәкәтендә һәрберебезгә дә бәхетле тормышлар насыйп әйләсәң иде!

**Илдар ЗИННӘТУЛЛИН.**

*(“Татар мөселман календаре”ннан)*

# Дога кыла беләсеңме?

## Дога кайчан кабул була?

Раббыбызга ярдәм сорап һәрвакыт мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Дога өчен билгеле бер вакыт юк. Әмма Мөхәммәд галәйһиссәләм дога кылу өчен кайбер аеруча кулай вакытлар турында хәбәр калдырган.

1. Коръән укыганнан соң.
2. Азан белән камәт арасы.
3. Сәхәр вакыты, төн уртасыннан соң.
4. Гарәфә көннәре.
5. Коръәнне башыннан ахырына кадәр укыгач.
6. Сәҗдә вакытында.
7. Беренче тапкыр Кәгъбәне күргәндә.
8. Җомга төннәре.
9. Бәйрәм төннәре.
10. Рамазан-шәриф ае.
11. Фарыз намазлардан соң.
12. Ялгыз, янында кеше булмаган вакытта, аулакта.
13. Яңгыр яуган вакытларда.

### Кемнәрнеке кабул була?

Аллаһы Тәгаләнең яраткан, догалары кабул ителә торган кешеләр түбәндәгеләр:

1. Әти-әнисенең балаларына догалары.
2. Балаларның әти-әниләре хозурына укыганы.
3. Коръән әһеленең, Коръән-хафизның догасы.
4. Үзе югында берәр кешенең артыннан укылган дога.
5. Мәзлүм, рәнҗетелгән кешенең догасы.
6. Уразалы мөселманның догасы.
7. Хасталарның догасы.
8. Игелек күргән кешенең догасы.
9. Хаҗиларның догасы.
10. Кайгы-хәсрәтле кешенең догасы һ.б.

Акыллары камил булган мөселманнар догадан бер сулыштан артык ераклашмаслар, һәрвакыт доганың кадерен, дәрәҗәсен белерләр. Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм һәр эшендә, һәр хәрәкәтендә Аллаһы Тәгаләгә догада булган. Дин кардәшләребез, һәркайсыгызга мәгълүм, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең догалары бик күп, без дә доганың кадерен белергә тиешбез.

### Шартлары:

Догасының кабул булуын теләгән һәр мөселман менә шушы шартларны үтәргә тиеш:

1. Бөтен гөнаһлардан тәүбә итү.
2. Догадан алда берәр хәер вә савап эшләү.
3. Доганы түбәнчелек һәм ихластан кылу.
4. Доганы тәһарәтләнеп, кыйблага юнәлеп, тез өстендә торып кылу.
5. Дога укыганда намаздагы кебек хушланып,